МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

17.02.2022 № 36

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 28.01.2019 № 38 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы 28.01.2019 № 38 боерыгы (Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы 29.05.2019 № 216, 04.12.2019 № 435, 30.11.2021 № 403 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктының икенче абзацында «30 көнлек срокта» сүзләрен «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокта» сүзләренә алыштырырга;

6.7 пунктының икенче абзацында «30 көнлек срокта» сүзләрен «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокта» сүзләренә алыштырырга;

6.8 пунктының икенче абзацында «30 көнлек срокта» сүзләрен «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокта» сүзләренә алыштырырга.

2. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
башкаручы Т.В. Кәримуллин